ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЕЛАБУГА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.04.2019 № 7

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан алына торган бүтән бюджетара трансфертлар акчасы хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны юнәлдерү турында

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бүтән бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 12 апрелендәге 557 номерлы карары нигезендә, һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешенә этәргеч бирү максатларында Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан алына торган бүтән бюджетара трансфертлар акчасы хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның түбәндәгеләр өчен юнәлдерелүен расларга:

1) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен;

2) Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсенә тапшырылганда муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен;

3) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15.1 статьясы нигезендә җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгәннәрен хәл итү өчен.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3. Бу карар үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче К.В. Мокшин